СӨЙ ТОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

*19 ноябрь, 1997ел.*
*ЧӘРШӘМБЕ*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 130 (8142)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

# БЕР ЭШНЕ ДӘ ЧИРАТКА КУЙМЫЙК



Вячеслав Зиновьевич Норлат шикәр заводының механикалаштыру бүлегендә эшли. Техника серләрен камил үзләштергән, хезмәтен сөеп башкаручы кеше буларак характерлыйлар аны предприятиедә.

Быел Вячеслав Зиновьевич хезмәттәшләренә икенче ягы белән дә ачылды. Баксаң, ул шикәр житештерүгә бәйле механизмнардан тыш, катлаулы авыл хуҗалыгы техникасын да әйбәт белә икән. Агымдагы җәйдә МТС тагы җыелма отряд составында комбайнчы булып эшләгәндә аерымачык тоелды бу. Герасимов «Кейс» комбайнын тиз арада үзләштереп хуҗалыклар басуларында сезон буе югары житештерүчән эшләде. Комбайны бункерыннан 25.200 центнер ашлык бушатты.

Вячеслав бүген дә «Кейс»ында эшли: бөртеккә дип үстерелгән кукуруз плантацияләреннән уңыш җыя ул.

**Рәсемдә: В.Герасимов.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Яңалыклар

### Мәдрәсә ачылды

Узган атнада шикәрчеләр бистәсендәге 1290нчы мәхәллә мәчете каршында мәдрәсә ачылды. Байтак ассоциацияләр һәм предприятиеләр, аерым гражданнар белән кыска вакыт эчендә төзелгән бу объект 50 кеше укытуга исәпләнгән. Озаклламый биредә укулар да башланачак. Мәчетнең төп корпусы төзелеп бетмәү сәбәпле мәдрәсә әлегә картларның гыйбадәт кылу урыны булып хезмәт итә.

Тантанага бистәдәге халык һәм чакырылган кунаклар җыелган. Шулай ук район хакимиятеннән, шәһәр җирле үзидарәсеннән рәсми вәкилләр килгән иде. Халыкка дин белемен өйрәтү, киләчәк буын мөселман кешесенең аңына ислам гореф - гадәтләрен сеңдерү, кануннарын үтәүгә өндәүгә юнәлтеләчәк бу бинага алар үзләренең бүләкләрен тапшырдылар.

### Яшүсмерләр көч сынашты

Узган якшәмбедә физик хәзерлек буенча балалар - яшүсмерләр клубында район мәктәпләре арасында татарча көрәш буенча район ярышлары булып узды. Анда Югары һәм Түбән Норлат, Чулпан, Фома, Яңа Әмзә, Богдашкино, Зирекле мәктәпләре укучылары, болардан тыш клубта спортның бу төре белән шөгыльләнүче төрле мәктәпләр яшүсмерләре катнашты. Егетләр 10 үлчәү категориясенә бүленеп көч сынаштылар.

# БУРЫЧЛАР ШУЛ УК КАЛА

Район хакимиятендә хуҗалык рәисләре һәм предприятие җитәкчеләре белән бергә уздырылган соңгы киңәшмәдә көннең төп бурычларыннан булган эшләр - чөгендер ташуны һәм бөртеккә калдырылган кукуруз уңышын җыеп алуны тәмамлау, шул ук вакытта терлекчелекне, бигрәк тә сөт җитештерү һәм хәзерләүне игътибар үзәгенә алу зарурлыгы турында сүз барган иде. Бу дүшәмбедә үткән киңәшмәдә дә шул ук мәсьәләләр үзәктә торды.

Гаять авыр шартларда булса да, казылган чөгендерне заводка озату дәвам итә. Игенчеләребезнең түземлелегенә, аларга ярдәмгә килгән автотранспортчыларның сабырлыгына сокланмый мөмкин түгел. Дөрес, техниканы бераз гына булса да киеренкерәк рәвештә файдаланганда, ягъни эшне бик иртә туктатмаганда да ярар иде. Югыйсә, чөгендерне иң күп мәйданда игүче «Кикле»дә озатыласы чимал да өч мең тоннадан күбрәк әле, «1 нче Май», «Родина», «Үрнәк», «Заря» хуҗалыкларында, нефтебаза ярдәмче хуҗалыгында ташылмаган чөгендер шактый. Булган бар чөгендер дә урнаштырылып бетсә, район буенча хәзерләнгән шикәр чималының 100 мең тоннадан артып китәчәге бәхәссез. Чөгендер озатуны катлаулы шартларда да уңышлы оештырган Синдряков исемендәге хуҗалык, аларның күршеләре «1 нче Май» дәүләт заказын бер - ике көндә тутырырга да мөмкиннәр. Тагын берничә хуҗалыкның моңа реаль мөмкинлеге бар. Шуңа да бу эштәге һәркемнең инде күпкә тырышканны азга гына түзүе бик кирәк. Кар өстеннән йөреп кукуруз суктыручы «Кейс»чыларның да фидакарьлеге хөрмәткә лаек. Билгеле, эш бер хөрмәт белән генә калмаячак, әлбәттә. Район җитәкчелеге авыл халкына хезмәт хакы буенча бурычларны кайтару җәһәтеннән эшлекле чаралар күрә. Шуңа күрә терлекчелектә эшләүчеләрнең дә бераз гына сабырлык белән үз вазифаларын җиренә җиткереп башкарулары сорала. Дөрес, соңгы вакытта сөт терлекчелегендә эшләрнең мактанырлык булмавы терлекче-ләрнең шәхси хез-мәтеннән бигрәк тармакка җитәкчеләр һәм белгечләр тарафыннан игътибарның йомшаруы нәтиҗәсе булып тора. Иң аянычы шул, савым сыерларының рационы ярлы, техниканың кыр эшләренә тартылган булуын сәбәп итеп, малларга азык кирәк кадәр кайтарылмый. Бу салкын көннәрдә кардаларда салам артыгы белән торырга тиешле бер вакытта кайбер хуҗалыкларда рацион шул тупас азыктан әллә ни ерак китми әле. Ә инде малларның асларына түшәү турында сүз дә алып барып булмый. Кызганычка каршы, киңәшмәдә җавап тоткан җитәкчеләрнең кайсыларыннан хәлнең кайчан яхшырырга мөмкинлеге турында төпле җавап та ишетергә туры килмәде әле. Ә бит кыенлыкларга карамастан эшне җиренә җиткереп оештырган хуҗалыкларда нәтиҗәләр бүген дә ярыйсы ук әйбәт һәм былтыргы практикага кире кайтып, андыйларның эш тәҗрибәсен башкаларга да җиткерү буенча чаралар күрми булмас ахрысы.

Көн тәртибендәге мөһим мәсьәләләр буенча киңәшмәдә хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев, авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе башлыгы Ф.М.Дәүләтшин чыгыш ясадылар. Хакимият аппараты җитәкчесе Ф.М.Галимов авылда үзгәртеп корулар үткәрү буенча бурычларның җитдилегенә басым ясады. Киңәшмәдә шулай ук газлаштыруның быелгы программасын үтәү, техниканы саклауга кую һәм төзәтә башлауга керешү җәһәтеннән дә сүз булды.

# •РУСИЯДӘ •ТАТАРСТАНДА

### *Рудольф Нуриев... Мәскәүгә килде*

Мәскәүдә мәшһүр балет биючесе Рудольф Нуриев иҗатына һәм аның тормыш юлына багышланган күргәзмә ачылды. Анда артистның шәхси әйберләре дә күрсәтелде.

### *Гәзит эчләрендә гәзит*

Татарстанда «Московский комсомолец в Татарстане» дигән яңа гәзитнең беренче саны дөнья күрде.

### *Композитор туган иленә җыена*

Дөньякүләм танылган композитор София Гобәйдуллина 1998 елның мартында Казанда үтәчәк «Аурупа - Азия» фестиваленә килергә ризалык белдерде. Якташыбыз хәзер Германиядә яши.

### *140 грамм ком өчен... 20 мең*

Көньяк Сахалинскида яшәүче Н.Сизов Красноярскига тугыз тартма кызыл балык уылдыгы сатырга килә. Карап торышка бу банкалар нәкъ заводта эшләнгән кебек, этикеткасы да бар. Сизов шәһәр эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре эләктергәнче базарда һәрберсен 20 меңнән 100гә якын банка уылдык сатарга өлгерә.

Чынлыкта бу банкаларга уылдык урынына елга комы тутырылган булып чыга. Н.Сизов бу уылдыкларны очсыз гына бәягә, акча эшләп алу максаты белән Көньяк Сахалинск базарында сатып алдым дип аклана.

### *Фонд чакыруы буенча*

Ичкерия Президенты Аслан Масхадов Карнеги фонды чакыруы буенча Вашингтонга килде. Бу визит вакытында АКШ дәүләт департаменты вәкилләре аның белән Грозныйдагы ОБСЕ миссиясе һәм башка мәсьәләләр хакында фикер алышачаклар.

### *7дән алып 70кә кадәр*

Түбәндә сифилис авыруы йоктырган кешеләр саны 2 меңнән ашып киткән. Авыручыларның иң өлкәненә 70 яшьтән артык, иң яше - 7 яшьлек көчләнгән малай.

## Яңалыклар

### Газ - шикәрчеләр поселогында

Бу көннәрдә шикәрчеләр поселогының Тукай, Маяковский урамнары һәм Циолковский урамының бер өлешендә торак йортларны газлаштыру эшләре тәгәлләнде дияргә мөмкин. Анда яшәүче, үткән елда ярты кыштан салкында утырып калган шактый хуҗа бүген зәңгәр ягулыктан килгән җылыга тиенде. Бу урамнарны газлаштыру эшләрен килешү буенча «Востокмонтаж» АҖнең Отрадныйдагы 2 нче төзелеш участогы һәм Әлмәт шәһәре СКБУ төзелеш участогы башкарып чыкты.

## Яңалыклар

### Аксубай - Норлат - Самара

Элек норлатлылар Самарага Норлат - Самара рейсы белән генә баралар иде. Аксубай - Самара транзит маршруты ачылгач, әлеге автобус бик уңайлы вакыт - иртән 8 тулганда Норлат автовокзалы янына тукталып, Самарага баручы пассажирларны да утырта китә.

### Андреевкада - имтихан

Биш елга бер килә торган фронталь тикшерү Андреевка мәктәбенә дә килеп җитте. Бүген район мәгариф бүлеге хезмәткәрләре Андреевка мәктәбендә укыту - тәрбия эшенең куелышын өйрәнәләр.

# Терәк булып бер - берсенә

Аларның гаилә коруларына кырык ел инде. Ул вакыт эчендә төрлесе булгандыр инде булуын, шулай да уңай хатирәләр дистәләрчә тапкыр күбрәк. Ә инде аларның гаилә ныклыгын саклап торган сәбәпләрнең иң мөһиме ир белән хатынның гомер буе бер - берсенә терәк булырга тырышуларында, бер - берсенең мәшәкатьләрен уртак итешә белүдә, бер - берсен начарлыклардан саклый алуда һәм, гади генә итеп әйткәндә, үзара яратышуда дип уйлыйм. Нәкъ менә шушы хисләр байлыгы шулкадәр зур аларда, бер селтәнүдә тузгытып ташланырга мөмкин булган матди байлыкка караганда күпкә өстен күреләр дә ул. Нәкъ менә хисләр - аларның терәге, таянычы, гаилә тоткасы.



1962 нче ел. Казаковлар кызлары Ира белән.

## Валентина Васильевна

Хәзер генә Валентина Васильевна ул, инде ике кызы да олылар, оныклары да өчәү. Ә ул чакта Валя - Валюша гына була ул. Һәм Якушкинога бергә йөреп укыган Ерепкино егетләреннән берсе бөтен кызлар арасыннан нәкъ менә аңа күз ата. Мәктәпне тәмамлагач Валя Ульяновскига, фармацевтлыкка укырга китә. Имтиханнарны өч кыз бергә тапшыралар, тик араларыннан Зоя, кечкенә генә үлчәүне төзәтергә кушулары белән үк документларын кире алып кайтып китә, ә Валентиналар икесе дә калалар. Ул арада Петр армиягә китә һәм араларында хатлар йөри башлый. Укып чыккач Валяны Алатырьдагы бер аптекага эшкә билгелиләр, шунда ук агач эшкәртү заводы һәм 25 урынлык сырхауханә дә була. Күптәннән килә торган үз гадәтләре булган бу як халкы да кешеләргә ачык йөзле, игътибарлы Валяны бик тиз үз итә. Аптека мөдире Иван Павлович та ошата кызны. Ачык күңелле булса да артык кысмыр кеше була үзе. Берчакны шулай Валя саксызлык белән аптеканың бер пыяла савытын төшереп вата. Шуның өчен күпме сүз ишетә ул... Шулай да Иван Павловичтан күп нәрсәгә өйрәнә Валя, тормыш сабакларын шактый ала. Шул сабакларның берсен гомергә онытасы юк... Аптекага бик еш бер карт кергәләп йөри, йөрәгеннән зарлануы. Булмаган табибы калмаган инде, ә авыртуы һаман да басылмый. Шунда аптека мөдире бу картка бер шешәгә дистилляцияләнгән су салып, көнгә өч тапкыр берәр аш кашыгы эчәргә дип бирергә куша. Бер атнадан тагын килә теге карт һәм рәхмәт укый кызларга, нинди хикмәтле дару бирдегез сез миңа, йөрәк авыртуым басылды бит, тынычлап йоклый башладым, ди. Менә бит ул кешене ышандыра алу кодрәте ничек...

Петр Васильевич белән туйны көзен ясыйлар алар. Аңа кадәр Петр армиядән кайтышлый ук, өенә дә кермичә аның янына килеп киткән була, шул чакта килешеп тә куялар. Октябрьнең бик матур, яфраклар көзнең алтынсу төсенә кергән көне була ул. Яшьләр иң җитез юртак ат Вайгачны тарантаска җигәләр дә, Аксумлага, авыл Советына юл тоталар. Ул чакта әле балдаклар алмашып торырлык чамалары булмый, кәләшкә тыйнак кына күлмәкне дә апасы гына тегеп бирә.

Тату гына яшәп китәләр Казаковлар. Яшь хатын аш - суга оста булып чыга, юк - бардан табыш чыгармый, ирне - ир итә белә, аның мавыгуларын да якын күрә. Кышын ул чаңгы ярышларына чыгып китсә, кечкенәләре Иришканы чанага утыртып, Валя да аның финишка килүен карап торырга чыга. Аннан Галя туа. Курчак кебек кенә була инде үзе, хәтта курчагының туфлие дә ярый үзенә.

Валентина Васильевна 94 нче үзәк аптекада ассистент булып эшли, ә 72 нче елда ул чактагы баш табиб аны район шифаханәсе аптекасына күчәргә күндерә. Рәхмәтләрнең хезмәт кенәгәсенә язылганнары да аз түгел, шулай да аның ярдәменә мохтаҗларның үз авызларыннан ишетелгәннәре күбрәк. Аларын нинди генә рәсми кәгазьгә дә кертеп бетереп булмый шул.

## Петр Васильевич

Петр Васльевичның тормыш фәлсәфәсенә килсәк, аның бар гомере үзе тапкан һәм сынаган, бернинди ялган да катышмаган кануннарга нигезләнгән. Спорт - аның гомерлек алласы да, юлдашы да шул. Малай чагыннан ук мавыгып китә ул спорт белән. Анысы болай булып чыга. Сугыш вакытында Тумбадан Ерепкино аркылы фронтка чаңгылар озаталар. Шул чакта дүрт стакан тозга алыштырып (ул чакта моның нинди бәя икәнлеген әйтеп тә торасы юктыр) бер пар чаңгы алырга күндерә ул әнисен. Бик тиз шомара ул чаңгыда, эт алып җибәрәләр дә, шуны ияртеп ауга йөри башлый, аннан инде җиде чакрымдагы мәктәпле авылга. 10 километрга чабуда мәктәп беренчелегенә ярышларда җиңеп чыгудан канатланып йөргән чагында, 1952 елның 12 гыйнварында телеграмма килеп төшә: Петр Казаковка район даның якларга Казанга барырга. Әмма болай да юклы - барлы гына яшәп торганда Казан хәтле Казанга чыгып китүе җиңел булмый, билгеле. Чабата киеп чыгып китә Петр. Аның каравы абзыйсы үреп биргән таза чабатасы юк - бар гына аяк киемнәренә биргесез була. Беренче көнне 79 районнан 43 команда катнаша. Ул эстафета узышының соңгы, дүртенче этабында чаба. Петрның шулкадәр җитезлегенә гаҗәпләнгән хөкемдарлар аны башка кеше урынына чапмый микән дип шиккә дә төшәләр хәтта. Ул чакта аны җылы чаңгы костюмы белән бүләклиләр. Бик тә кадерле дә, яраклы да бүләк була ул аның өчен. Һәм шуннан бирле үзе күпме ярышларда катнашмасын, күпме шәкертләрен стартка чыгармасын, шул беренче уңыш китергән зур ярышны гомергә онытмый ул.

1963 елда Казаков СССР халыкларының III спартакиадасында катнаша. Марафон дистанциясенә йөгерә. 42 чакрым 195 метрлы шул араны ике сәгать ярымда чабып чыкканда биш килога җиңеләеп кала ул. Ә врач: "Синдәге бу йөрәк белән марафонда чабарга түгел, аюга каршы чыгарга була" ди. Шул көннең истәлеге булып аңарда "Спорт һәркайда һәм һәрвакыт" дигән альбом саклана. Ул чакта бер дусты Казанда очраткан булган ул альбомны һәм бер рәсемдә Петрны күреп сатып алган. Спартакиада фотографы шулай җиңел йөгерүче җитди йөзле Казаковны тәки эләктереп алган булган икән бит.

... Спорт. Кайда гына эшләмәсен - Норлат шикәр заводын төзүдәме, ДОСААФның район комитетындамы, мәктәптә укытудамы - Петр Васильевичның гомере чаңгы, тимераякта йөрү, йөгерү, волейбол, йөзү, граната ыргыту һәм башка спорт төрләре белән аерылгысыз. Спорт аңа нык сәламәтлек, яхшы кәеф бүләк итә, яшәргә җегәр бирә. Петр Васильевичның үз гомерендә грипп белән авырганы юк, ә больничныйга берзаман радикулит китереп кыскач кына чыккан.

Спорт. Ул аның характерын да сыный, аны үз алдына максат куеп, шуңа ирешергә дә өйрәтә. Яулаган һәр җиңүе аңа үз характерында яңа бер сыйфат ачарга мөмкинлек һәм яңа үрләргә күтәрелергә көч бирә, егәр өстәп тора. Берәр сәгатькә яки көнгә генә түгел, ә гомере буена.

Спорт. Ул аңа шатлык та китерә, яңа дуслар табарга да булыша, дөньяга карашын да киңәйтә. Петр Васильевич йөзләрчә малайлар һәм кызларны да спорт дөньясына алып кереп китә. Һәр якшәмбене спорт залларында, стадионнарда һәм чаңгы юлларында үткәрә ул, гомер буе сәгатьне санап торганы булмый. Декабрьдә иртәнге дүрттә мәктәп шугалагында боз катыра торган була ул. Һәм шәкертләре аны әле дә онытмыйлар, бәйрәм саен котлаулар җибәреп торалар, очрашканда кәефен сорашмый калмыйлар. Спортка мәхәббәтне гомер буе саклый алган Петр Васильевич аларның күпләре өчен өлге бит!

Спорт. Аңа бүген дә кадерле әле ул. Әле өченче ел кыш чаңгыда меңъярым чакрым чапкан. Иртән күнегүләр ясый. Велосипедтан да аерылганы юк. Пәнҗешәмбе саен сәгать ярым - ике сәгать волейбол уйнап ала. Аның үзен "аяклы энциклопедия" дип йөртәләр - хоккейчыларыбызның кайчан ничек җиңгәнлекләрен һәм җиңелүләрен, олимпиадаларда алтын медаль алучыларны, пятиборьечыларның , җиңел атлетларның һәм чаңгычыларның рекордларын хәтерли. Аның хәтерендә йөзләрчә дата һәм фамилия, күпсанлы цифрлар һәм аны аңлаган кешеләр генә рәтенә төшенердәй күпсанлы башка спорт статистикасы мәгълүматлары. 48дән бирле "Спартак" яклы ул. Телевизордан чираттагы матч бара икән, аларның фатирында тормыш бөтенләй икенче рәвешкә керә, йорттагылар ишаралап кенә сөйләшәләр.

Спорт. Бүген Петр Васильевичны спортның позицияләре йомшару бик нык борчый. Кайчандыр районда югары белемле бер физкультура укытучысы булса да, спортта нәтиҗәләр һәм казанышлар бар иде, дип искә ала ул. «Шул елларда абруйлы спортчыларыбыз барлыкка килде: велосипедчы Илья Паруков, йөгерешче Василий Таймуллин, спорт мастерлары Горелов, Ляпунов, Гордеев, Ильин һәм башкалар; "Урожай" футбол командасы 15 ел буе республикада иң яхшылар исәбендә булды... Хәзер тренерлар дистәләп, ә күрсәткечләр юк. Карт гвардия яшьләрдән яңа нәтиҗәләр көтә дә бит..."

***

**Казаковлар гаиләсенә кырык ел. Гомер узганы сизелмәгән дә. Туганнарын онытмыйлар, бәйрәмнәрдә дуслары белән җыелышалар, яздан көзгә чаклы бакчада мәш киләләр. Һаман да икесе бер сукмактан, бергә һәм янәшә, ялгансыз, шул ук вакытта матур булса да буш сүзләрсез атлауда алар. Үзләре дә уйлавынча, башкалар да әйтүенчә, бәхетле, изге күңелләрен тупаслындырмыйча, иң матур хисләрен җуймыйча яшиләр. Ни кирәк ди тагын?**

**Т.НАЗАРОВА.**

---

**● Газета укучы рәхмәт әйтә ● Газета укучы рәхмәт әйтә ● Газета укучы рәхмәт әйтә ● Газета укучы рәхмәт әйтә ●**

## ЯХШЫЛАРЫ - КҮБРӘК

Миңа, өлкән яшьтәге сугыш инвалидына, соңгы вакытта табиблар хезмәтеннән еш файдаланырга туры килә. Сөенеп кайтам, районыбыз табиблары арасында үз хезмәтен әйбәт белүче белгечләр байтак. Хирургия бүлеге мөдире А.В. Слепцов, яшь белгеч Камалов авыруларга ихтирамлы карашы белән башкалардан аерылып торалар.

И.С.Таһиров куйган диагноз да һәрчак рас туры килә. Белемле һәм тәҗрибәле хирург Ә.К.Сафиуллинга да ышанычым зур минем. С.Ә. Волкова киңәшләрен дә һәрчак тотам.

Соңгы елларда стоматология бүлеге дә күзгә күренеп үзгәрде. Аның мөдире Р.Ә. Мостафин кабинетларны камил заманча җиһазлар белән баетуга зур өлеш кертте, үз янына белемле кадрлар җыйды. Халыкка намуслы хезмәт итәләр алар.

Иске Чаллы участок шифаханәсендә дәваланырга да туры килде миңа. Биредә дә медицина персоналы хәзерлекле, белемле. Үзләренә мөрәҗәгать итүчеләргә югары профессиональ дәрәҗәдә медицина хезмәте күрсәтү өчен барысын да эшлиләр алар. Шуңа да телгә алып үтелгән барлык медицина хезмәткәрләренә олы рәхмәтемне җиткереп, аларның үзләренә дә сәламәтлек, тынычлык телисем килә.

**И.ТУИШЕВ.**
**Норлат шәһәре.**

